ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.07.2024 г.Лениногорск № 196

«Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2016 елның 7 декабрендәге 84 номерлы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы карары белән кабул ителгәнТатарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2016 елның 7 декабрендәге 84 номерлы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең яңа редакциядәге , кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры

Р.Г. Хөсәенов

1нче кушмта

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 31 августындагы 196 номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1) 6 статьяда:**

**1 өлешнең 27 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

**часть 1 дополнить пунктом 37** следующего содержания:

«37) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

**2) 6.3 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

**3) 10 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында** «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе « сүзләренә алмаштырырга»;

**4) 11 статьяның 4 өлешендә** «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

**5) 15.1 статьяда:**

**5 өлештә** «Җирлек сайлау комиссиясен» сүзләрен «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга»;

**8 өлештә** «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

**12 өлештә** «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

**6) 20 статьяның 7 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында** «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты « сүзләрен төшереп калдырырга»;

**7) 22 статьяның 1 өлешендә** «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга»;

**8) в части 1 статье 23:**

**16 пунктны** үз көчен югалткан дип танырга;

**33 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

**9) 30 статьяның 1** өлешен түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт белән тулыландырырга:
«10.1) аның чит ил агенты статусын алуына;»;

**10) 33 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты « сүзләрен төшереп калдырырга;**

**11) 39 статьяның 9 пунктындагы икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: «балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра,

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра; «;

**12) 48 статьяны** үз көчен югалткан дип танырга;

**13) 53 статьяның 3 өлешендә** «һәм Җирлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

**14) 66 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«66 статья.** Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1.Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып тора:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru;ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында ФС77-60244 номерлы таныклык бирелгән 17.12.2013 Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә вакытлы матбугат басмасында «Лениногорские вести», «Заман сулышы»газеталарына рәсми бастырып чыгару;

2) Лениногорск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (http://leninogorsk.tatarstan.ru) урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: Лениногорск шәһәре, Шашин урамы, 41 йорт – «Үзәкләштерелгән китапханә системасы».

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза

салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, челтәр басмаларының исемлеге «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгының, Лениногорск шәһәре мэрының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга кадәр җиткерелә.»;

**15) 68 статьяны** үз көчен югалткан дип танырга.